# Я , я хәрефе



Елмаеп карагыз дөньяга,
Рәхәт бит яшәве, шулаймы?!
Елмаеп яшәсәң көн саен,
Укырга, уйларга бик җайлы.

Аю, юкә,
юлбарыс, юрган,
ютәл, юмарт, юка.



Көндез ул начар күрә,
Нәкъ менә шуңа күрә,
Үз корбанын сагалап,
Төнлә тора чамалап
Бу нинди кош?

# ЯБАЛАК



*Язын дөньяга килә,*
*Көзен саргаеп үлә.*

# ЯФРАК




*Лампа түгел яктырта,*
*Мич түгел җылыта.*

# КОЯШ



*Ялт-йолт ялтырый,*
*Җирнең өсте калтырый,*
*Энҗе кебек тезелә,*
*Ефәк кебек сузыла.*


ЯШЕН


я
йа
йә



# я

[йа] [йә]

яна яшел


ялкын яшен






**Яя**

*Я я*





Кояш, кыяр ,

дөя, куян,

бияләй, чия.

# Физминутка







# Мәкальләр

1. Яхшы сүз җанга рәхәт,
   Яман сүз җанга җәрәхәт.
2. Ялкау ятып эшли,
   Утырып йоклый.
3. Аннан моннан эшләсәң,
   Яңадан эшләрсең.

**Схема бунча сөйлә:**

**Мин ….белдем .**
**….истә калдырдым .**
**Эшли алдым.**

**Авыр булды.**

Әфәрин!